СОВЕТ КОРГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАРАГУЖА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

07.09.2018 | с. Коргуза | 47-200

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында" гы карары проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегендә халык алдында тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Советының 23.10.2017 ел, № 31-149 карары нигезендә, авыл җирлегендә яшәүчеләрнең халык алдында тыңлаулар үткәрү юлы белән проект турында фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатыннан,

Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» гы Карары проектын 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә һәм аны халык алдында тыңлауларга чыгарырга.

2. Расларга:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» гы карары

проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен №2 кушымта нигезендә;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибен №3 нче кушымта нигезендә.

3. 2018 нче елның 12 нче октябрендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карахгуҗа авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.

4. Башкарма комитетка Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегендә яшәүчеләрнең тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Советына карауга кертергә.

5. 2018 елның 10 сентябренә кадәр әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru), Карагуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Совет рәисе
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы С. А. Сакин